**Исмаил Гаспринский и русификаторская политика правительства (конец XIX - начало XX вв.)**

В статье рассматривается отношение видного татарского просветителя И.Гаспринского к русификаторской политике царского правительства на рубеже XIX - XX вв.

Заһидуллин И. **И.Гаспралы һәм хөкүмәтнең руслаштыру сәясәте** // Мирас, 1992. – № 5.

Патша самодержавиесенең милли изү тарихында татарлар аерым урын алып тора. Бу гыйбрәтле тарихның беренче сәхифәләре татар халкы бәйсезлеген югалтудан башлана.

Империядәге милли изү сәясәте халыкара хәлне, илнең эчке халәтен исәпкә алып үткәрелә. Бу изү Россиядәге күпмилләтле халыкның барысына да тигез төшми, хәтта мөселман халыклары арасында да аның үз аерымлыклары, үзенчәлекләре бик ачык күренеп тора.

Ислам дине Россиядә түбән, аз хокуклы диннәрдән санала. Шуның өстенә империянең көньякта яулап алуларына гел комачау итеп килгән мөселман дәүләте – Төркия дә берничә гасыр дәвамында дошман сыйфатында кабул ителә. Идел буеның XIX гасырга кадәр үк эчке Россия саналуы, дәүләт чигенең ерак булуы, татар халкының өч йөз ел буена урыс изүенә “ияләнүе” патша хөкүмәтенә Идел буе татарлары өстендә урыслаштыру буенча тәҗрибәләрне беренчеләрдән булып үткәрергә мөмкинлек бирә.

XIX йөзнең икенче яртысында Россиядә башланган буржуаз үзгәртеп корулар, капитализм үсеше, илдәге иҗтимагый хәлнең җанлана башлавы урыслаштыру сәясәтенә дә үзгәрешләр кертми калмый. Хәер, аны югарыда аталган сәбәпләр белән генә аңлатып булмый. Татар милләте оешу үзенең соңгы этабына керә. Милли аң үсешенең бер чагылышы итеп керәшеннәрнең кире мөселманлыкка кайту хәрәкәтен атарга була. Моңа каршы рус чиновниклары яңа керәш формалары эзләргә мәҗбүр булалар. Рус зыялыларының берсе, миссионер Н.И.Ильминский дөньякүләм, бигрәк тә Англиянең бай һәм күп тапкырлар сыналган колониаль изү тәҗрибәсен киң файдаланып, христиан динен җирле “инородец”ларга сеңдерү методикасын эшли. Ул тәкъдим иткән система нигезендә кириллица белән җирле халыклар телендә басылган дини китаплар чыгару, мәктәпнең башлангыч классларында христиан дине нигезләрен татар телендә үзләштерү ята. Аның фикеренчә, урыс динен, тарихын, гореф-гадәтләрен генә таныган “инородец”, урысча әйбәт сөйләшмәсә дә, ул инде манкортка әверелә, күңеле белән “урыслашкан” була. Бу фикернең дөреслеген вакыт һәм тормыш раслады инде. Шулай итеп, халыкның динен алыштыру – урыслаштыруның беренче этабы, урыс телен белү – икенче һәм соңгы этабы булып санала башлый. Диннән соң урыслаштыруда икенче мөһим алым – урыс халкының бөеклеге, аның рухи яктан өстенлеге турындагы фикерне “инородец”лар күңеленә оеткы итеп салу, ышандыру була[1].

60 нчы елларның икенче яртысыннан башлап керәшен авылларында күпләп кон-фессиональ мәктәпләр ачу күзәтелә. Моңарчы мәҗбүр итүгә корылган христианлаштыру сәясәтендә камчы seberке белән алыштырыла. Ләкин себеркенең озын һәм авыр сабы татар халкының төп өлешенә – мөселманнар белән мөселманлыкка кайткан керәшеннәргә суга башлый.

1867 елның 4 октябрендә Казанда оешкан “Изге Гурий кардәшлеген” акыллы, җирле халыкларның телен; гореф-гадәтләрен яхшы белгән, уз эшенә бирелгән кешеләр – миссионерлар җитәкли. Патша хөкүмәтенең башка идарә итү органнарыннан аермалы буларак, әлеге җәмгыять бюрократик эш алымнарыннан арынырга омтыла. Шуңа күрә татарга, мәсәлән, моңарчы яшәп килгән җирле власть вәкилләренә, дин әһелләренә ришвәт биреп, законсыз рәвештә мәчетләр, гыйбадәтханәләр ачу мөмкинлеге бетерелә.

Җирле халыкларны мөселманнар йогынтысыннан саклау, мөселманлыкка чыгу куркынычын бетерү сылтавы астында Ильминский җитәкчелегендәге миссионерлар, православие дин әһелләре, губерна администрациясе, Казан уку-укыту округының попечителе күп тапкырлар югары властьларга Диния нәзарәтен бетереп, аның эшләрен губерна идарәләренә тапшыру, мәчетләрне төзетмәү, муллаларның санын киметү, татар милли мәктәбен кысу, мөселманлыкка кайткан керәшеннәрне күпләп Себергә сөрү, мөселманнарның сайланырга хокуклары булган волость идарәләренә, хәтта авыл старосталары итеп христиан дине вәкилләрен кую һ.б. тәкъдимнәр белән чыгалар.

Конкрет алып караганда Ильминский методикасы ул чорда әле татар халкының уннан берен дә тәшкил итмәгән керәшеннәргә юнәлдерелгән була. Аның тарафдарларының мөселманнарга карата мөнәсәбәтен “урыс телендә сөйләшә алмаган фанатик – урыс телендә белеме булган интеллигент татардан яхшырак, аристократ – куркынычрак, университет белеме булганнары – моннан да куркыныч”[2], – дигән сүзләр бик ачык күрсәтеп тора.

Патша Екатерина II нең дин иреге турындагы указыннан соң мөселман диненә тыкшынудан туктаган патша хөкүмәте XIX гасырның икенче яртысында үз сәясәтен яңарта. 1866 елда Казанга килгән халык мәгарифе министры граф Д.А.Толстойга татарның үзенә бер дөнья булып, урыс йогынтысына бирелмичә көн күрүе бер дә ошамый. Мондый бэйсезлекнең нигезендә татар милли мәктәбе белән мөселман руханилар эшчәнлеге ятканын яхшы аңлаган хөкүмәт үзенең урыслаштыру сәясәтен шушы ике “куркыныч” көчкә каршы оештыра. И.Гаспралы сүзләре белән әйткәндә, “мөселман дөньясына, аның тормыш һәм фикер үсешенә йогынтысы теләсә нинди Европа университетлары-ныкына караганда да чагыштыргысыз дәрәҗәдә көчлерәк”[3] булган татар мәктәбенә һөҗүм башлана.

Урыс булмаган халыкларга аң-белем таратуның ахыргы максаты ачыктан-ачык “урыслаштыру һәм урыс халкына кушу”[4] дип игълан ителә. 1870 елда Халык мәгарифе министрлыгы эшләгән программа “агарту” эшен ике юнәлештә: чукындырылган “инородец”лар һәм мөселманнар арасында алып баруны күздә тота. Мөселманнарны урыслаштыру фәкать урыс телен өйрәтү аркылы гына мөмкин, дип ассызыклап әйтелә. Программага училищеларда татар балалары өчен әзерлек класслары булдыру, мәктәпләрдә мәҗбүри рәвештә урыс класслары ачу, 1870 елдан башлап яңа мәктәпләрне андый класстан башка ачтырмау, урыс теле укытучысын тоту буенча чыгымнарны авыл мәхәлләсенә йөкләү кебек пунктлар кертелә. 1881 елдан ул чыгымнар 350 сумнан ким булмаска тиеш дип билгеләнә һәм урыс классын ачуга каршылык булган очракта рәсми рәвештә андый татар мәктәбен ябарга рөхсәт бирелә[5].

1870 елның 26 мартында патша тарафыннан расланган законга Мәгариф министрлыгы тәкъдим иткән – дин әһелләре урынына, җирле идарә органнарына, земстволарга һәм башка хөкүмәт оешмаларына урыс телен генә белгән мөселманнарны билгеләү кебек мәсьәләләр кертелми. Татар белән эш итүдә зур тәҗрибә туплаган самодержавие урыслаштыру сәясәтендә акрынлап басымны көчәйтә бару юлын сайлый. Урыслаштыруның үзәгенә әйләнергә тиеш булган классларда кадрлар мәсьәләсен хәл итү максатыннан, “христиан диненә юл ачар өчен”, эксперимент рәвешендә 1876 елда Казан татар укытучылар мәктәбе ачыла. Татар дөньясын яхшы белгән Н.И.Ильминский дөньяви белем бирүгә корылган урыслаштыруны баштан ук “зыянлы” итеп игълан итә һәм мәктәпкә акча бүлеп бирүне тыярга тырыша.

Империянең хәрәкәткә китерелгән урыслаштыру машинасының эшчәнлегенә каршы чыккан татарларны буйсындыру һәм эш барышын тизләтер өчен 1874 елда татар мәктәпләре Халык мәгарифе карамагына тапшырыла, ә 1882 елдан алар өстеннән министрлык контроле урнаштырыла. Указлы муллаларны раслаганда Казан губернаторы өчен аларның урыс класслары ачуга мөнәсәбәте зур әһәмияткә ия була башлый. Буйсынырга ашыкмаган татар халкын урыслаштыруны дин әһелләреннән башларга һәм алар аркылы тәэсир итәргә карар кылына. 1891 елдан

алып руханилардан дәүләт телен белү таләп итела.

Урыслаштыру сәясәте татар халкы тарафыннан чукындыруга әзерлек дип кабул ителә һәм кискен каршылыкка очрый. XX гасыр башында татар милләтенең чын мәгънәсендә уянуы, фикер күтәрелеше, иҗтимагый тормышның җанлануы – җәмгыятьнең урыслаштыруны үз эченә үткәрмичә сәламәт калуына турыдан-туры бәйле. XIX йөзнең икенче яртысында милләтне саклап калуда кадимче муллаларның роле зур була. Без сүз алып барган чорда кадимче дип аталган дин әһелләренең татар халкын урыслаштырудан саклап калудагы ролен Явыз Иван яулап алуыннан башлап XVI–XIX гасырларда диңгездәге корабны көчле җил-давыл кыйбласыннан аерып үзе белән алып китүдән саклаган якорь белән чагыштырып булыр иде. Ә инде XIX йөз ахыры – XX гасыр башында кадимчеләр бераз басылган давылга буйсынмаган, үз юлын, үз мәсләген эзләп кузгала башлаган корабка кирәге булмаган, аны торган урыныннан җибәрмәскә азапланган авыр йөк хәлендә кала.

Идел буе мөселманнарына шундый сәясәт алып барылган бер вакытта 1883 елда Кырымда – Бакчасарай шәһәрендә мөселманнар арасында беренче газета – “Тәрҗеман” чыга башлый. Аны алдынгы карашлы, Парижда, Истанбулда аң-белем җыйган, берничә тел белгән, журналист һәм публицист булып танылган Исмәгыйль Гаспралы нәшер итә.

Аңарчы Казанда, Петербургта татарча газета чыгарырга күпләр талпынып карый. Мәсәлән, архивта Казан университеты адъюнкты И.И.Запольскийның (1808), шул ук университетны тәмамлаган М.Г.Никольскийның (1834) гаризалары саклана. Җаны-тә-не белән халыкка урыс тарихын, мәдәниятен якынайтырга тырышкан күренекле татар мәгърифәтчесе Каюм Насыйриның да “Таң йолдызы” дип исемләнгән газета чыгару теләге тормышка ашмый. Тышкы эшләр министрлыгында татар теле тәрҗемәчесе булып эшләүче П.Н.Пашино һ.б. гаризаларына кире җавап алына[6]. Югарыда аталган шәхесләр үзләренең патша хөкүмәтенә ышанычлылык, бирелгәнлек ягыннан И.Гаспралыдан ким түгелләр. Патша чиновниклары сүзләре белән әйтсәк, хикмәт шәхестә түгел[7], газетаның нинди халыкка хезмәт итүендә.

Беренче Россия революциясе ташкыны патша самодержавиесенең сәяси һәм икътисади тормышка демократияне үткәрмәүче субайлары белән бергә, татар халкының мәгърифәтен буып, газета чыгаруны тыеп торган авыр бастырыкны да алып ташлый. Татарча газета чыгарырга беренче омтылыштан соң тулы бер гасыр вакланып бетеп килгәндә генә урыс һәм татар зыялыларының хыялын тормышка ашырырга насыйп була.

И.Гаспралыга газета чыгарырга рөхсәт биреп властьлар тышкы һәм эчке сәясәттә берничә куян атарга чамалыйлар. “Тәрҗеманның нәшер ителә башлавы һәм ябылмавы мөселманнарның дин иреге турында сөйләп кенә күзгә төтен җибәрер заманнар узганын аңлаган патша хөкүмәтенә, төньяк күршеләренең мөстәкыйльлекләрен югалтуга риза булмаган, христиан дәүләте, итеге астында калган мөселманнарның хокукый хәлен яхшырту турында сөйләүче Төркия һ.б. илләргә, ислам динен тотучы “инородец” газета чыгара, дип төртеп күрсәтергә мөмкинлек бирә.

Инглизләр, французлар тәэсире нәтиҗәсендә Төркиянең икътисадында һәм сәясәтендә “европалашу” иҗтимагый тормышта һәм ислам динендә яңарышка китерә. Бу үзгәрешләр Кырым татарларының, алар белән күрше башка мөселман халыкларының мәдәни һәм гомумән рухи яктан Төркияне үз кыйблалары итеп күрүне көчәйтә. Бу очракта аның йогынтысын киметү һәм үз сәясәтен җирле халыкларга җиткерү өчен патша хөкүмәтенә чын күңелдән бирелгән, сыналган берәр мөселманга матбугат органы оештырырга рөхсәт бирүдән дә кулай вариант юк кебек. Бер үк вакытта бу Россия мөселманнарына урыс патшасы кайгыртуын раслау да була. Әлбәттә, монда И.Гаспралының акыллы, газетаның дәүләт өчен файдалы булачагын ышандыра торган гаризаларын һәм үҗәтлек дәрәҗәсендәге эшчәнлеген билгеләп үтми мөмкин түгел.

Россия эчендә милли изү сәясәте үзенең даимилеге белән аерылып тора. Тышкы сәясәттә, киресенчә, XVI йөздән бирле тупланып килгән яулап алу

тәҗрибәсе, дәүләтара мөнәсәбәтләрдә җилнең кайсы яктан искәнен чамалап, аның юнәлеше үзгәргән очракта ашыкмый, ләкин тиз хәрәкәт итү, ахыргы максатка ирешү өчен беркадәр ташламаларга баруның кирәк булуын күрсәтә. Кырымда җирле халык телендә дә газета нәшер ителү халыкара хәлне исәпкә алуның бер чагылышы була.

Кырымда "Тәрҗеман" чыга башлауга ун ай да үтми, И.Гаспралы эшчәнлеген бик тиз бәяләп өлгергән Н.И.Ильминский дусты һәм хезмәттәше Синод обер-прокуроры К.П.Победоносцевка хат юллый. Баш миссионер Гаспралыны Европа мәдәниятен таратуда, Россия буенча таралып утырган мөселманнарны берләштерергә тырышуда һәм барысы өчен дә бер тел – төрек теле кертергә, илдә мөселманнарның милли мәдәни үзәген төзергә омтылуда гаепли. Соңгы вакытта Казанда күбәя башлаган төрек китапларын Гаспралы эшчәнлеге белән аңлата[8].

1894 елда Казан татар укытучылар мәктәбе инспекторы Шаһбазгәрәй Әхмәровның газета чыгарырга рөхсәт сорап язган гаризасына үз фикерен белдергәндә Казан уку-укыту округы попечителе бу эшнең киләчәктә татарлар арасында хөкүмәткә файдасы булмаган үзгәрешләр китереп чыгарачагын ассызыклап билгеләп үтә. Мисалга ул инде 12 ел нәшер ителүче "Тәрҗеман"ны китерә. И.Гаспралының мөселман мәдәниятен яңа биеклекләргә күтәрергә, татарның милли үзаңын үстерергә тырышуын Кырым, Себер, Казан һ.б. як татарларын берләштерергә омтылу дип күрсәтә. "Матбугат сүзенең милләтне сакларга хезмәт итүе һәм милли рухны үстерүе, – ди ул, – закон тарафыннан тыела һәм дәүләт күзлегеннән караганда зыянлы"[9].

Үзенең программасы бик лояль булуга, урыс телендә дә чыгуына, цензура аша үткәрелүгә дә карамастан, "Тәрҗеман" хөкүмәтнең өметен акламый. Хикмәт монда, күрәсең, урыс цензурасы ул вакытта әле бик ук аңлап бетермәгән, беренче карашка шул заман идеология калыпларыннан читкә чыкмыйча басылган мәкаләләргә икенчел мәгънә–милли хис, милләтне уяту мәгънәсе салынудадыр.

"Тәрҗеман"ның, мәсәлән, 20 еллык эшчәнлеген шундый яссылыкка салып караганда иу юнәлешләрне анык билгеләргә була. Иң мөһим дигәннәреннән – урыс телен белергә өндәү, мәктәп реформасын үткәрү буенча эшчәнлек, дөньяви фәннәрне өйрәнергә чакыру, халык өчен фәнни һәм дөньяви китаплар чыгаруны арттырырга тырышуны атап булыр иде. Газетадагы язмалардан югарыда аталган бурычларны тормышка ашыруга юнәлдерелгән кайбер алымнарны төсмерләргә дә була.

И.Гаспралы, мөселманнарга карата хөкүмәт үткәрә торган сәясәтне инкарь итмичә, татарның артта калуында төп гаепне аның үзендә, милләт турында кайгыртмавында, надан муллалар булуда күрә. Милләт оешуның төп шартларыннан берсе булган халык сөйләменең китапка күчә баруын, әдәби телнең ныгуын тели. Бу өлкәдә Г.Барудины бигрәк тә күренекле мәгърифәтче К.Насыйрины үрнәк итеп куя[10]. Моңарчы күбрәк дини китаплар белән канәгатьләнгән татарларда 80 нче еллардан башлап дөньяви фәннәр буенча уку китаплары басыла башлауны китап чыгаруда зур борылыш башла ну-милләт үсешенең мөһим шарты дип бәяли[11]. Муса Акъегетнең "Хисаметдин менла", Заһир Бигиевнең "Меңнәр, яки Гүзәл кыз Хәдичә", Фатих Халидинең "Рәдде бичара кыз" кебек мәгърифәтчелек реализмына караган әсәрләрне И.Гаспралы татар матур әдәбиятын үз язына илтүче беренче умырзаялар дип кабул итә, татар дөньясының иҗтимагый һәм әдәби тормышында аларның һәрберсен мөһим вакыйга дип билгеләп үтә.

Татарның беренче тарихчысы Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләрен, аның үткәнне өйрәнү буенча эшчәнлеген югары бәяләгән язмаларда "Тәрҗеман" битләрендә басыла[12].

Илдәге ачлык, ялангачлык, ришвәтчелек, тормышның тискәре күренешләре, рус халкы көнкүреше дә "Тәрҗеман"да ничек бар, шулай яктыртыла. Газетада хатын-кызның җәмгыятьтә тоткан урыны, мәдәният үсеше, медицина хезмәтенең куелышы һ.б. турындагы язмалардан рус укучысын да алдынгы Европа илләреннән үрнәк алып мәдәниятне үстерүгә чакыру ярылып ята. Ләкин татарларга әлеге язмалардан үзләренә өлге булырга тиешле урыс халкының хәле әллә ни мактанырлык түгел

икәне күренә һәм власть вәкилләре моның урыслаштыруга ярдәм итмәвен яхшы аңлый. Мисалга Төркия яки гарәп илләре китерелсә, моны урыс чиновниклары панисламизм тарату, дип атый. Мәсәлән, татарның беренче роман язучысы М.Акъегет, гимназия белеме белән Россия университетына кермичә, укырга Төркиягә киткәч, аны Н.И.Ильминский поляк кызына гашыйк булып илен саткан Тарас Бульбаның улы Андрей белән чагыштыра[13].

И.Гаспралының тагын бер уңай эшчәнлеген билгеләп үтәргә кирәк. Ул морза Дәүләткильдеев, ахун Гатаулла Баязитов белән бергә, урыс укучысына ислам дине тотучы халыкларның фанатик түгеллеген, ислам динендә булган өчен генә аларны артта калган, дип уйларга ярамаганны, мөселманнарның киләчәктә алдынгы урыннарда булачагын белдерә. Миссионерларның, шовинистларның. Коръәндәге аерым сүзләргә нигезләнеп, татарның урыс кешесенә, урыс дәүләтенә дини дошман булуы хакында "теоретик" фараз кылуларын кире кагу "Тәрҗеман" битләрендә кызыл җеп булып сузылган[14]. Гадәттә И.Гаспралы урыс газеталарында мөселманнарны кимсетә торган мәкаләләргә каршы чыга һәм шундыйларның берсендә редакторларны элементар әдәп кагыйдәләрен сакларга чакыра[15].

"Тәрҗеман"да Төркия, гарәп илләре тарихыннан, андагы аерым шәхесләр, тормыш-көнкүреш, прогресс хакында мәкаләләр, хәбәрләр эзлекле рәвештә басылып килә. Бу эш, күрәсең, бер яктан, мөселманнар хакында берьяклы гына мәгълүмат алган урыс укучысын "агарту", мөселман халкы тормышы белән якыннанрак таныштыру өчен эшләнсә, икенче яктан, Россиядә яшәүче ислам динен тотучыларга шул халыклар мисалында яңа идеяләр үткәрү өчен файдаланыла.

"Тәрҗеман" редакторы Россиядә генә түгел, Европа илләрендә дә мөселман хатын-кызларына карата киң таралган ялкаулык, ирләрнең колы булып бикләнеп яшәү кебек карашларга каршы чыга, аларның йорт эшләрен алып баруда, балалар тәрбияләүдәге зур ролен билгеләп үтә. Ислам дине ир-ат белән хатын-кыз мөнәсәбәтендә кырыслыкка чакырса да, мондый хәлне ул җәмгыятьтәге хезмәт бүленешенең бер чагылышы дип карый. Мөселман хатын-кызларының бигрәк тә чит илләрдә акрынлап җәмгыять эшләренә тартылуын күрсәтә.

Әлбәттә, XX йөз башында илдә иҗтимагый тормыш уңай якка үзгәрешләр кичергән чорда И.Гаспралыга үз фикерләрен ачыктан-ачык әйтергә, сүздән эшкә күчәргә мөмкинлек туа. XIX йөзнең соңгы чирегендә исә И.Гаспралы, татар халкының иҗтимагый-сәяси яктан хәлсез организмын терелтерлек, бер үк вакытта милләт эчендә кирәкмәс тискәре процесслар башланмаслык итеп, тиешле күләмдә дару һәм тәэсирле сүз белән эш иткән табип рәвешендә күз алдына килә. 1891 елда басылган мәкаләләрнең берсендә И.Гаспралы үзенең тактик алымын халыкны акрынлап прогресска алып бару, артык зур һәм куркытырлык идеяләр күтәрмичә генә хәрәкәт итү белән чагыштыра. Шушы алымны сайларга мәҗбүр иткән төп сәбәп "Тәрҗеман" битләрендә чагылып-чагылып кита. Кайбер урыс газеталары, мөселман дөньясына кагылышлы шовинистик рухлы мәкаләләрен дәлилле итеп төзәтеп килгән "Тәрҗеман"ны яптыру өчен, аның урысча һәм татарча нөсхәләрендә төгәлсезлекләр китүдә, фикерләре рәсми хөкүмәт үткәргән милли сәясәткә тәңгәл килмәүдә редактор Гаспралыны гаепләп чыгалар.

Яңалык яклылар татар халкының культуралы һәм бай яшәвен өмет итеп, белемгә, чит телләрне өйрәнергә чакыралар. Бер үк вакытта И.Гаспралы мөселманнарны урысның гомуми белем бирү мәктәбенә, ягъни гимназияләргә һәм югары уку йортларына түгел, ә Европа фәне Коръән белән үрелеп татарларның үз туган телендә укытыла торган махсус белем учакларына өнди. Ул, бер яктан, татар культурасына Европа йогынтысын көчәйтергә, татар дөньясына алдынгы фәнни агым алып керергә, татар яшьләрен европача укымышлы, булдыклы зыялылар белән бер баскычка куярга омтылса, икенче яктан, бу олы эшне, халыкның милли йөзен саклап калган хәлдә, Европа ирешкәнне татар мәдәнияте аша үткәреп милләтнең үсүенә хезмәт иттерергә тели. Җәдит мәктәпләрендә урыс теленең "бөек" халыкка якынаю өчен түгел, ә башка фәннәр белән беррәттән милли мәдәниятне үстерү максатында кулланыла башлавы XIX гасыр ахырында патша

чиновникларын аерата нык борчый. Җыеп әйткәндә, бу яңалыклар патша хөкүмәтенең урыслаштыру сәясәтен миллəт өчен файдаланырга омтылу була.

XIX гасырның икенче яртысында урыслаштыру сәясәтенә И. Гаспралының карашы нинди булган соң? Бу сорауга җавапның бер өлешен аның 1881 елда дөнья күргән "Русское мусульманство" дигән китабыннан табарга мөмкин. Автор татар мәдәниятенең мәгарифенең артта калуын, элекке заманнардан да кайтышрак хәлгә килүен иң элек урыс хакимиятеннән күрә Хөкүмәтне илнең үсешенә зур өлеш керткән татарларга йөз белән борылырга чакыра. Икенче сәбәпне И.Гаспралы татарның үзеннән эзли. Урыс тормышын белмәве, аңламавы, илдәге иҗтимагый тормышка якынаеп, кушылып китә алмавы татарның үсешен тоткарлый, дип саный.

И.Гаспралы, урыслаштыру сәясәтенең кайбер якларына тукталып, урыс мәктәбе, ислам дине булган татар мәхәлләсендә төрле кысу, кимсетү юлы белән максатка ирешеп булмаячагын әйтә. Ул, ислам динен өйрәнүне тыйган очракта, аның гаилә эченә күчәчәген, руханига указ алуны тыюның файдасызлыгын, мәчетләр төзергә рөхсәт бирмәү халыкның гыйбадәтләрне өйдә үткәрә башлавына китерәчәген, китап басуга каршы чыгу кульъязмаларны файдалануга илтәчәген, мондый алымнар хөкүмәткә карата тискәре караш, ышанмаучылык, эчке көрәштән башка берни -дә бирмәячәген аңлата

Милләтләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең якынаюын күздә тотып, И.Гаспралы мөселманнарга карата аны "рухи яктан урыслашу" дип атый. Аны тормышка ашыру, ягъни урыс халкы тормышын, законнарны белү, аңлау өчен татарның үз мәдәниятен үстерергә мөмкинлек бирү кирәклеге мәсьәләсен куя .

Мәгърифәтченең урыс телен өйрәнүгә карашын билгеләгәндә, аның түбәндәге фикерләрен исәпкә алырга кирәк, һәр кеше 5-6 тел белергә тиеш. Шулардан иң мөһим дигәннәреннән – туган тел, үзе яшәгән дәүләтнең теле, ул заманда халыкара тел оу-лып танылган француз теле. Фән-техника заманында дәүләт телен белү һәр милләт өчен зарур һәм файдалы. Госманлы дәүләттә яшәүче әрмәннәр, яһүдиләр h. б. халыклар да төрек телен өйрәнергә мәҗбүрләр, дип яза ул. Дәүләт телен өйрәнүне Гаспралы татар милли мәгариф системасының әһәмиятле бер өлеше дип кабул итә. Шул ук вакытта, 70 иче еллардан башлап Идел буе мөселманнары мәктәпләрендә көчләп урыс класслары, урыс-татар мәктәпләре ачуга корылган урыслаштыру сәясәтенә үзенең тискәре мөнәсәбәтен белдерә. Аларны үле туган оешма, дип атый, мәктәпнең фәкать белем һәм әхлакый тәрбия алу урыны икәнен, башка максатлар өчен аны файдаланырга ярамаганны кистереп әйтә. Хөкүмәт алдында татар мәктәбендә укыту теле итеп урыс телен түгел, ә татар телен кертергә кирәклеген, бу алымның дәүләт теле булган урыс теленә бер зыян да китермәячәген күтәреп чыга.

"Тәрҗеман" битләрендә Гаспралының татар мәктәпләрен Халык мәгарифе министрлыгы кулына тапшыруга карата тискәре фикерләре дә чагылыш тапкан. Ул, Казан уку-укыту округында бу өлкәдә җыелган тәҗрибә, илнең көньягында яшәүче мөселманнарга да күчерелә башлагач, әлеге адымның уңай нәтиҗә бирмәячәген тагын бер кат раслый. Татарда көчләп урыс класслары булдырып түгел, ә алдынгы карашлы мөгаллимнәр тарафыннан халыкның үз теләге белән ачылган урыс класслары, урыс-татар мәктәпләре аркылы, аларга хөкүмәттән ярдәм булганда гына мәгариф өлкәсендә урыстагы казанышларны кертергә мөмкин икәнен күрсәтә.

XX йөз башында цензура тикшерүе йомшап, үз фикереңне әйтергә мөмкинлек тугач, И.Гаспралы Казан уку-укыту округына караган губерналардагы татар мәктәпләрен Халык мәгарифе министрлыгына тапшыруга 30 ел тулу уңаеннан, бу адымның бернинди нәтиҗәсе булмавын, хөкүмәт урысча укытуны оештыру түгел, ә урыс-татар мәктәпләренең тышкы кыяфәтен яхшырту, аларны финанслау буенча да бармакка-бармак сукмавын белдерә. Монда, әлбәттә, татар халкының үз каршылыгын да исәпкә алырга кирәк: И.Гаспралының фикереңчә, соңгы чирек гасыр эчендә татарларга карата алып барылган хөкүмәт сәясәте мөселманнарны бер тамчы да урыслаштырмый, киресенчә, аларда Россиягә карата ышанычны какшата, киләчәк язмышлары өчен курку гына тудыра. Үз фикерен дәвам итеп ул, Ильминский

ишеләр тәкъдим иткән, татарның үз мәдәниятен үстермичә генә, киләчәктә дә урыслаштыру системасын куллану Россиядә бөтен җитдилеге һәм катлаулылыгы белән мөселманнар мәсьәләсен чыгарачагын әйтә.

Татар дөньясын прогресска, алга алып баручы көч итеп И.Гаспралы зыялыларны, алдынгы карашлы муллаларны саный. Дин нигезләрен, гарәп телен яхшы белгән, прогрессив карашлы, намуслы мулла авторитетын, дәүләт тарафыннан бирелгән казыйлык, укытучылык, дин тарату хокукларын файдаланып, үз мәхәлләсенә зур хезмәт күрсәтә ала, дип белдерә. Ә татар дөньясының шундый кечкенә мәхәлләләрдән торганын исәпкә алсак, дин әһелләренең роле тагын да ачыграк күренә. Шуңа күрә И.Гаспралы күпчелеге белән кадимче булган руханиларга урысча өйрәтергә кирәклеген яклап чыга. Урысча белүне ул җәдитчеләр санын ишәйтүгә ярдәм итүче алым буларак кабул итә. һәм мөфти Солтановка мөрәҗәгать итеп, хөкүмәт карарын үтәү белән бергә, белем турындагы ценз (чикләү) закон көченә кергәндә мәхәлләләр муллasыз калмасын, дин ирегe кысылу килеп чыкмасын өчен руханиларны имтиханга әзерләндерү-дә алдан ук хәстәрен күрергә чакыра. Шул максат белән Уфада Үзәк мәдрәсә-училище ачарга тәкъдим ясый.

Патша чиновникларының “Тәрҗеман”га тискәре мөнәсәбәтен фәкать андагы мәкаләләргә генә кайтарып калдырсак, бу бик тар һәм берьяклы фикерләү булыр иде. Мондый тискәре реакциянең төп сәбәбен Кырымнан торып таратылган мәгърифәт орлыкларының уңдырышлы Идел буе туфрагына төшеп, аң-белемгэ омтылган милләт уллары тырышлыгы белән. Россиядә төрки халыклар арасында беренчеләрдән булып тиз арада куе һәм көчле шытым бирүеннән дә эзләргә кирәк.

Күренекле мәгърифәтче, журналист, җәмәгать эшлеклесе И.Гаспралының патша хөкүмәте үткәргән урыслаштыру сәясәтенә мөнәсәбәтенә ике яктан бәя биреп була. Бер яктан, патша хөкүмәте сәясәтенә турыдан-туры каршы чыкмаса да, И.Гаспралы аны үткәрү методлары белән килешмәвен белдерә. Патша чиновниклары башта татар халкын мәгърифәтеннән, мәдәниятеннән, тарихыннан, диненнән яздырып, шул бушлыкны урысныкы белән тутырырга теләсәләр, И.Гаспралы халкыбызның үз йөзен саклап калырга тырыша. Икенче яктан, И.Гаспралы патша самодержавиесенең урыслаштыру сәясәтен милләтнең үз файдасына кулланырга омтыла, ягъни урыс телен, мәдәниятен белә торган, урыс фәне, промышленносте ирешкәнне татар халкы өчен файдаланырлык, алдынгы карашлы, зыялы яшьләр тәрбияләү, урыс тормышындагы уңай якларны татар дөньясына күчерү, урыс укыту системасы үрнәгендә татар мәгарифен үзгәртеп кору турында хыяллана, үзенең бөтен сәләтен, тырышлыгын шушы эшкә багышлый.

Татарларның бүген аерым милләт буларак яшәвендә, телен, динен, мәдәниятен. тарихын саклап калуында үзенең бөтен гомерен төрки халыкларга хезмәт итүгә багышлаган Исмәгыйль Гаспралының өлеше зур.

## ФАЙДАЛАНЫЛГАН ЧЫГАНАКЛАР


[1] Сборник документов и статей по вопросу об образовании инородцев. — СПб, 1869, 9 б.

[2] Ильминский Н. И. Письма Николая Ивановича Ильминского к обер-прокурору Св. Синода К. П. Победоносцеву. – Казан, 1895, 175 б.

[3] Гаспринский И. Русское мусульманство. – Оксфорд, 1985, 67 б.

[4] Материалы по истории Татарии. – Вып. 1. М.-Л., 1936, 285 б.

[5] Фәхретдииов Р. Исламнар хакында хөкүмәт тәдбирләре. – Оренбург, 1908, 1 кис., 22 б.

[6] Каримуллин А.Г. Татарская книга пореформенной России. –Казан, 1983, 179 – 198 бб.

[7] ТССР ҮДА, 1 ф., 3 тасв., 9690 эш, 6 б.

[8] Ильминский Н.И. Письма... 63–64 бб.

[9] ТССР ҮДА, 1 ф., 3 тасв., 9690 эш, 5–6 бб.

[10] Тәрҗеман, 1891, 27 январь һ. б.

[11] Тәрҗеман, 1891, 18 январь, 3 октябрь; 1897, 3 март.
[12] Тәрҗеман, 1886, 26 декабрь; 1889, 28 апрель.
[13] Илъминский Н.И. Письма... 310–311 бб.
[14] Тәрҗеман, 1891, 27 январь, 2 апрель, 30 август, 13 декабрь: 1892, 29 март, 4 декабрь; 1897, 31 март; 1898, 20 сентябрь.
[15] Тәрҗеман,1889, №43, 10 декабря.